ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.11.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4454**

Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 21 сентябрендәге «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 820 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 августындагы 1557 номерлы, 2022 елның 17 гыйнварындагы 42 номерлы, 2022 елның 29 сентябрендәге 2560 номерлы, 2022 елның 14 октябрендәге 2730 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 3624 номерлы, 2024 елның 30 маендагы 1418 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен 2025 елның 01 гыйнварыннан арттырырга.
2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмасындагы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазифаи оклады күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм аның күләмен 13 990 сум күләмендә билгеләргә.
3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин